ТЫНЫЧЛЫК КАЧТЫ

Мәктәпләргә кем яный?

> 2

САЛА ДА САНЛАША

Хәзер сыерны да робот сава

> 2



ВЯЧЕСЛАВ ДАНИЛОВ

Тау ягының катлаулы һәм фаҗигале тарихы турында

> 4

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

«Күрәләр икән – син бар, күрмиләр икән – юк»

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 21 (28794) | Шимбә | 12 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Хезмәттәшлек

Бер айда ике тапкыр очрашу. Гыйнвар ахырында Татарстан Президенты Казахстанга сәфәр кылган иде. Анда Рөстәм Миңнеханов бу ил башлыгы Касыйм-Җомарт Токаев белән дә очрашты. Казахстан Президенты Хөкүмәт үзгәрсә дә, хезмәттәшлекнең алга таба дәвам итәчәген, «КамАЗ» һәм «Татнефть» проектларына ярдәм буласын әйтте. Бер ай да узмады, Токаев үзе дә Татарстанга килде.

tatarstan.ru

УРТАК ЭШ

Аның Мәскәүдән соң Казанга юл тотуы гаҗәп түгел. Әлеге сәфәр – татар белән казах арасында тарихтан килгән мөнәсәбәтләрнең чагылышы да, ул Татарстанның ил төбәкләре арасында аерым урын алып торуын да тагын бер кат раслый. Тарих димәктән, рәсми очрашу алдыннан Касыйм-Җомарт Токаевка Казан Кремлен күрсәттеләр. ЮНЕСКОның бөтендөнья мирасы исемлегенә кергән тарихи комплекс турында олуг кунакка Рөстәм Миңнеханов үзе сөйләде. Казахстан башлыгы Кремльнең истәлекле урыннарын күрде, әлбәттә инде, Кол Шәриф мәчетендә, Благовещение чиркәвендә булды. Кол Шәриф мәчетенең тарихы турында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, ә чиркәү турында – Казан һәм Татарстан митрополиты Кирилл сөйләде. Казахстан Президенты Казанга соклануын әйтте, мәчет белән православие чиркәвенең янәшә урнашуының үзенчәлекле символ булуына игътибар итте.

Экскурсиядән соң Татарстан Президенты Кремльдә Казахстан Президенты Касыйм-Җомарт Токаев белән очрашу уздырды.

– Игътибарыгызны һәм Казахстан белән хезмәттәшлекне үстерү мөмкинлеген югары бәялибез, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Казахстан – безнең өчен стратегик партнер. Сезнең төбәкләр белән күп кенә килешүләребез бар. Пандемиягә карамастан, товар әйләнеше инде ике ел рәттән 630 миллион доллар дәрәҗәсендә саклана. Әмма безнең мөмкинлекләр тагын да зуррак.

Хезмәттәшлек сату-алу, бизнес проектлары белән генә чикләнми. Татарстан Президенты Казахстанда Россиянең техник вузлары филиалларын ачу мәсьәләсенә дә тукталды. Юкка түгел, чөнки бу хакта Касыйм-Җомарт Токаев алдагы көнне Мәскәүдә үзе әйткән иде. Әлегә исә Татарстан вузларында Казахстаннан килгән 1,5 мең студент белем ала.

Рөстәм Миңнеханов Казахстанда 200 меңнән артыграк татарның яшәвен дә искә алды. «Алар әйбәт яши. Милләттәшләребезгә ярдәмегез өчен эчкерсез рәхмәт», – диде Татарстан Президенты. Рәхмәт димәктән, Рөстәм Миңнеханов ике арадагы хезмәттәшлекне үстерүгә керткән өлеше, ике халык арасындагы дуслыкны ныгытканы өчен Касыйм-Җомарт Токаевка «Дуслык» орденын тапшырды.

Казахстан Президенты, үз чиратында, Татарстанга килүенә шат булуын әйтте.

– Кичә Мәскәүдә Владимир Путин белән 5 сәгать чамасы сөйләшү үткәрдек. Татарстан белән хезмәттәшлекне дәвам итәчәгебезне әйттек. Владимир Владимирович Татарстанның Россиядә иң нык үсүче субъектларыннан берсе булуын әйтте, – диде ул. – Казанга әле тәүге килүем. Мәчеттә, православие чиркәвендә булдым. Сокландым. Сезнең җитәкчелектә Татарстанның ничек үсүен күреп торабыз.

Очрашу барышында «КамАЗ», «Татнефть» җитәкчеләре, профильле министрлар хәзерге вакытта тормышка ашырылып килүче уртак проектлар турында сөйләде.

Казаннан Касыйм-Җомарт Токаев Түбән Кама һәм Чаллыга юл тотты. Түбән Камада ул «ТАНЕКО» нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексында булды. Казахстан Президенты предприятие эшчәнлеге белән танышты, операцион үзәктә булды. Казахстан Президентына шулай ук «Татнефть» эшчәнлегенең башка юнәлешләре, аерым алганда, автомобиль шиннарын җитештерү турында сөйләделәр.

Исегезгә төшерәбез: «Татнефть» 2021 елдан Казахстанда шин производствосын булдыру проектын тормышка ашырып килә. Яңа заводта елына 3 миллион җиңел һәм җиңел-йөк машинасы, 500 мең йөк машинасы шиннарын җитештерү күздә тотыла. Заводны 2022 елның азагында ачу планлаштырыла. Анда 1,1 меңнән артыграк эш урыны булдырылачак. Касыйм-Җомарт Токаев яңа предприятиенең булачак хезмәткәрләре белән очрашты: хәзер алар Түбән Камада шин җитештерү нечкәлекләренә өйрәнә.

«КамАЗ»да Казахстан Президенты йөк автомобильләре җитештерүнең тулы циклы белән танышты. Касыйм-Җомарт Токаев двигательләр, кабиналар кысаларын җитештерү һәм автомобиль заводларында булды.

Моннан тыш олуг кунак Россия – Казахстан уртак предприятиесе белгечләре белән очрашты: Чаллыда алар хәзер стажировка уза. Шулай ук Касыйм-Җомарт Токаев Татарстанның сәнәгать предприятиеләре күргәзмәсен карады. Анда Яшел Үзән суднолар төзү заводы, Казан вертолет заводы, КМПО, Алабуга автомобиль заводы, «Соллерс Форд», «Аурус», «Химград» технополисы һ.б. катнаша.

Казахстан Республикасы базары «КамАЗ» өчен мөһим экспорт базарларыннан берсе булып тора. Узган елның 9 ае йомгаклары буенча, Казахстанның яңа йөк машиналары базарында «КамАЗ» өлеше 42 процент (1068 берәмлек) тәшкил иткән. «КамАЗ»ның Казахстан Республикасындагы производство-сервис челтәре җыю заводын, сәүдә компаниясен, 18 сервис үзәген һәм автомобильләр, запас частьлар буенча 28 дилерны үз эченә алган. Соңгы өч ел эчендә махсус техника җитештерү буенча ике монтажлау үзәге модернизацияләнгән. Кустанай һәм Атырау шәһәрләрендә ике сервис үзәген төзү планлаштырыла.

Бүген «КамАЗ» Казахстанда кайбер зур проектларны тормышка ашырып килә. Шуларның берсе – Кустанай шәһәренең индустриаль зонасында чуен коелмасы җитештерү буенча «KamLitKZ» заводын төзү. Биредә төзелеш эшләре дәвам итә. 2024 елның икенче яртыеллыгында сериялэп җитештерүне башлап җибәрү күздә тотыла. Шул ук индустриаль зонада тагын бер завод төзелеп килә.

Шулай итеп, Татарстан белән Казахстан арасындагы хезмәттәшлек сәүдә өлкәсе белән генә чикләнми. Үзара мөнәсәбәтләр уртак җитештерүне үстерүгә күчте.

Фәнгә игътибар арта

Россия Президенты Владимир Путин илдә фән һәм технологияләр унъеллыгын игълан итү тәкъдиме белән чыкты. Ул әлеге сорауны 31 мартка кадәр җентекләп өйрәнеп бетерергә кушты. Шул уңайдан доклад белән чыгыш ясау Президент администрациясе җитәкчесе Антон Вайнога йөкләнде.

Моңа кадәр Владимир Путин Дәүләт Советы белән мәгариф һәм фән советының уртак утырышында, фән елын игълан итү яңа «фәнни унъеллык»ны башларга нигез булыр иде, дип белдергән иде.

Шулай ук Владимир Путин Хөкүмәткә 15 июльгә кадәр фәнни хезмәткәрләр, шул исәптән югары уку йортлары педагоглары өчен ташламалы ипотека кредитына кагылышлы тәкъдимнәр әзерләргә кушты. Бу эштә Россия Премьер-министры Михаил Мишустин җаваплы итеп билгеләнгән.

Кар биеклеге нормадан арткан

Татарстан кырларында кар катламының биеклеге 28–70 сантиметр тәшкил итә. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, күпчелек районнарда ул нормадан артып киткән инде. «Россельхозцентр» филиалы җитәкчесе урынбасары Любовь Занина белдергәнчә, кырларда кар катламы калынлыгының 20–37 сантиметр булуы республика өчен норма санала.

Биек кар катламы уҗымнарның тамырлары тирәнлегендә температураны –0,2...–8 градус чикләрендә саклау мөмкинлеге бирә. Шул ук вакытта ул үсемлек тукымаларында шикәрнең күбрәк тотылуына китерә. Әлегә үсемлекләрдә шикәр микъдары 23,5–31 процент тәшкил итә. Бу – нормага туры килә торган күрсәткеч.

Җәнлекләргә – «ашханә»

Татарстанда кыргый хайваннар һәм кошларның исән-имин кышлавы өчен 9 меңнән артыграк җимлек булдырылган. «Кышкы чорда, табигатьтә азык бетеп торган бер мәлдә, тояклы хайваннар, куяннар һәм кошларны даими ашату мөһим. Шул сәбәпле комитет хезмәткәрләре кыргый хайваннарны тукландыруны оештырды. Бу эш бөтен республика территориясендә алып барыла. Җимлекләр кыр кәҗәләре, куян, көртлекләр, кайбер урыннарда кабан дуңгызларына исәпләнгән. Әмма аларга башка хайваннар да килә», – диделәр Биоресурслар буенча дәүләт комитеты матбугат хезмәтендә.

Бүгенгә республика территориясендә куян, көртлекләр өчен 9 мең «ашханә» булдырылган. Кыр кәҗәләренә, куяннарга 19 меңнән артыграк яфрак себеркесе әзерләп куелган. «Урман ашханәләре»ндә кыр кәҗәләре өчен тонналап печән һәм силос салып куелган, кошлар өчен 3,7 меңнән артыграк вак таш өеме һәм 5,3 меңнән күбрәк көлле ком өеме (кошларның ашкайнатуын яхшырту өчен) ясалган.

COVID-19

Артка карап, алны уйлыйсы

УЗГАН ТӘҮЛЕКТӘ ТАТАРСТАНДА КОРОНАВИРУСНЫҢ 2238 ОЧРАГЫ ТЕРКӘЛДЕ

Антитәнчекләр күләменә карап QR-код бирәчәкләр. Коронавируска бәйле соңгы яңалыкларның иң әһәмиятлесе шулдыр, мөгаен. Моны күптән көткәннәр иде бит. Тагын бер яңалык «больничный» кәгазенә кагыла. Хәер, барысы турында да рәттән аңлатыйк.



kzn.ru

Коронавируслы вазгыятьтә без әле кая барабыз? Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе белгечләре, үсәбез, ди. Чирләүчеләр санына кагыла бу.

– Татарстанда коронавирусның яңа очраклары кискен артты – узган тәүлек эчендә республикада коронавирус инфекциясе йоктыруның 2238 очрагы теркәлгән. Бу элеккерәк булган күрсәткечтән 513кә күбрәк. Чирләүчеләр санының артуы гыйнварның беренче атнасыннан башланган иде, – диде идарә башлыгы урынбасары Любовь Авдонина. – Киләсе ике атна кая таба баруыбызны билгеләячәк. Узган атнада үсеш темпы 2,8 иде, бу атнада 2 мәртәбә артык.

Коронавирусның ике штаммы арасында «омикрон» дигәне кешеләр белән ешрак «дуслашкан». Ул чир йоктыручыларның 73 процентында ачыкланган. «Дельта» штаммы – 26,5 процентында. Әле үткән атнада гына «омикрон»лылар саны 65 процент иде.

Медицина оешмаларындагы вазгыять турында шулай ук саннар сөйләп тора. Республикада коронавирусы сырхаулар өчен 4503 ятак булдырылган. Шуларның 6,2 проценты гына буш. Бу – 200ләп урын дигән сүз. Балалар өчен 385 урын булдырылган. 380ендә сырхаулар дәвалана.

Сүз уңаеннан, Татарстанда «больничный» кәгазен өйдән чыкмыйча гына рәсмиләштереп була. Республиканың баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов әйтүенчә, бу халыкка медицина ярдәменнән файдалану мөмкинлеген яхшырту нияте белән башкарыла. Моның өчен «122» номерына шалтыратып, гариза калдырырга кирәк. Бу гариза сырхауханәгә тапшырылачак һәм мөрәҗәгать итүчегә 7 көнлек «больничный» ачачаклар.

– Бу система вакытлыча эшли. 15 мартка кадәр дип торабыз. Шуны да әйтергә кирәк: ул бары тик ОРВИ билгеләре булганнар өчен генә гамәлдә. Башка авырулар өчен «больничный»ны бу ысул белән алу мөмкин түгел, – диде белгеч.

Тагын бер үзгәрешне 21 февральдән көтәсе. Бу көннән башлап чиргә каршы антитәнчекле кешеләр дә QR-кодлы белешмәгә ия булачак. Белешмәнең куллану вакыты алты айга исәпләнгән. Аны алу өчен «Дәүләт хезмәтләре» порталында гариза тутырырга кирәк булачак.

САН

Татарстанда 2430082 кешегә вакцина ясалган, шуларның 1896321е прививканың икенче дозасын алган. Кабат вакцинацияне 214506 кеше узган.

Сүзгә-сүз

Дмитрий МЕДВЕДЕВ, Россиянең Куркынычсызлык буенча Совет рәисе урынбасары:

Россиядә мигрантлар саны арта. 2021 елда ул өч тапкыр күбәйде. Моның сәбәбе: кайбер дәүләтләрдә ковидка каршы чараларның йомшаруы, кимүе. Ел саен Россиягә берничә миллион чит ил кешесе килә. Аларның күпчелеге – безнең ил белән чиктәш булган ил гражданнары.

(ТАСС)

ТОРМЫШЫГЫЗНЫ НӘРСӘДӘН БАШКА КҮЗ АЛДЫГЫЗГА КИТЕРМИСЕЗ?

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләргә әнә шул сорауны биргән.

Кер юу машинасы	46%
Смартфон	44%
Интернет	42%
Автомобиль	31%
Компьютер	21%

Яшелчә һәм чәй кыйммәтләнә

Дәүләт статистикасы хезмәте Татарстан идарәсенең 28 гыйнвардан 4 февральгә кадәр мәгълүматлары буенча, республикада кайбер төр продуктларга бәя арткан.

Әйтик, кыярның бер килосы 3,56 процентка кыйммәтләнгән. 169,58 сум торган кыяр хәзер 172,62 сумга җиткән. Кишернең бер килосы өчен 38,58 сум акча чыгарып саласы (арту – 1,9 процент). Моннан тыш кара чәйгә бәя 1,79 процентка арткан. Уртача алганда, бер кило чәй 874,62 сумга төшә икән.

Шоколад конфетлар – 1,71, кибет токмачы һәм кәбестә – 1,61, каймак – 1,47, шикәр комы – 1,42, маргарин – 1,38, сөт – 1,36, ә балалар өчен коры сөт катнашмаларының бәяләре 1 процентка арткан.

Шул ук вакытта чөгендер (3,57 процент), балалар өчен ит һәм яшелчә консервлары (1,47 һәм 1,23), бәрәңге (1,1), тавык итенең (1,03) бәяләре арзанайган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Акмаса да, тамган

Узган ел Татарстанның 583 предприятиесендә хезмәт хакы МРОТтан (эш хакының минималь күләме) да кимрәк түләнгән. Нәтиҗәдә 1381 кеше иң аз күләмдәге хезмәт хакы алган. Татарстанда Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская Дәүләт Советы утырышында шулай дип белдерде.

Татарстан Профсоюзлар федерациясе, Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы белән Министрлар Кабинеты арасында төзелгән өч яклы килешү нигезендә, республикада МРОТ күләме 15400 сум итеп билгеләнде, дип искә төшерде Сәрия Сабурская.

Гомумән алганда, Татарстанда эш хакын түләүне күз уңында тоталар: ведомствоара комиссияләр тәкъдиме белән 1731 хезмәткәргә барлыгы 5,9 миллион сум өстәп түләнгән.

Вәкаләтле вәкил эш хакын вакытында түләмәүне кискен проблема буларак телгә алып үтте. Узган елда хезмәт хакы буенча бурыч күләме 291 миллионнан 350 миллион сумга кадәрге чиктә булган. Кайбер айларда әлеге бурыч күләме 2020 елдагыга караганда да арткан: ул чагында максималь әҗәт 305 миллион сумны тәшкил иткән.

– Кешенең эш эзләүгә күпме вакыт исраф итүе дә, хокукларны үтәү күзлегеннән караганда, бик мөһим күрсәткеч, – диде Сәрия Сабурская. – Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, узган елда эшсез калган кешегә яңа хезмәт урыны эзләү өчен уртача 4 ай чамасы вакыт кирәк булган.

Хезмәт базарында күзәтелгән тагын бер күренеш – тулы көн эшләүчеләр саны арту. 2020 ел азагына республикада 20,5 мең кеше ярты көн генә эшләсә, 2021 елның октябренә аларның саны 15,5 меңгә калган.

Яшәеш

Эш тә, түләү дә арта

Татарстанда яшәүчеләр 2022 елның февраленнән элек социаль яклау бүлеге аша билгеләнгән түләүләрне Россия Пенсия фонды аша ала башладылар. Республикада әлеге акча 2 миллион кешегә бирелә. Моның өчен бер елга 120 млрд сум акча каралган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Пенсия фонды нинди түләүләрне башкара? Алар кемнәргә тиеш? Россия Пенсия фондының Татарстан буенча идарәчесе Эдуард Вафиннан шул хакта сораштык.

– Без түли торган акчаларны төрле категория кешеләр ала. Пенсия оешмасы аша 1,5 елга кадәр бала караган өчен түләү, эш урыны бетерелүгә бәйле рәвештә эштән чыгарылган хатын-кызларга йөклелек һәм бала табу буенча, бала туганда һәм сабыйны гаиләгә тәрбиягә биргәндә бер тапкыр бирелә торган, хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр түләнә торган һәм хәрби хезмәткәрнең баласына айлык пособиеләр бирелә, – диде Эудард Вафин. – Шулай ук түләүләрнең күп өлешен һәлак булган хәрбиләр һәм көч структурасы хезмәткәрләренең гаиләләренә бирелә торган түләүләр тәшкил итә. Төрле радиация аварияләрендә зыян күрүчеләргә дә хәзер тиешле пособиене безнең оешма түли.

Әлеге түләүләрне алыр өчен яңадан ниндидер гаризалар язу, документлар тапшыру кирәк түгел. Бөтен мәгълүмат Пенсия фондына автомат рәвештә күчкән. Ә менә быел гына пособие билгеләнгән кешеләргә инде Пенсия фондына мөрәҗәгать итәргә кирәк булачак.

– Әкренләп документ эшләре җайлана. Электронлашу кешеләрнең вакытын янда калдырачак. Аларга бер документ өчен әллә ничә җиргә барып йөрергә дә кирәкми хәзер. Пенсия фонды бар кирәкле язуларны төрле оешмалар аша үзе соратып ала башлаячак, – ди җитәкче.

Тагын бер күңелле хәбәр: 1 февральдән Россия Пенсия фонды күрсәтә торган социаль ярдәм чаралары 8,4 процентка индексацияләнде.

Беренче балага «ана капиталы» февральдән 40646 сумга артып, хәзер ул 524527,9 сумны тәшкил итә. Әгәр икенче бала 2020 елга кадәр туган яки уллыкка алынган ике балалы гаиләләрдә сертификат рәсмиләштерелмәгән яки аннан бер тапкыр да файдаланылмаган икән, бу гаиләләргә дә шундый ук сумма тиеш. Гаиләдә ике бала да 2020 елдан соң туган булса, «ана капиталы»ның күләме индексациядән соң 53712,27 сумга артып, 693144,1 сумны тәшкил итә.

Быел «ана капиталы» индексация хисабына 168616,2 сумга арткан. Бу арту әлегә кадәр сертификаттан файдаланмаган гаиләләргә дә кагыла.

Шулай ук февраль башыннан айлык акчалата түләүләр 8,4 процентка индексацияләнде. Республикада федераль ташламаларны 317,5 мең кеше ала. Акчалата түләү белән социаль хезмәтләр җыелмасы да, бәясе артып, аена 1313,44 сум тәшкил итә. Әлеге җыелмага дарулар, медицина кирәк-яраклары һәм инвалид балаларның туклануы, шифаханә-курортка юллама, шәһәр яны тимер юл транспортында бушлай йөрү, шәһәрара транспортта дәвалану урынына бушлай бару һәм кире кайту керә.

– Ташламалар суммасы айлык акчалата түләү составына керә, аны үзләренә тиешле кешеләр пенсия белән бергә алалар, – ди Эдуард Вафин.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

МӘКТӘП БЕЛӘН КЕМ УЙНЫЙ?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казан мәктәпләрендә балалары укыган әти-әниләрнең тагын тынычлыгы качты. Кичә кабат, берничә мәктәпкә шартлаткыч җайланмалар куелды, дигән хәбәр таралды. Шуңа күрә балаларны өйләренә кайтарып җибәргәннәр. Берничә көн элек тә мондый хатлар башкаланың берничә уку йортына килгән.

Шартлаткыч җайланмалар куелу турында аноним хатларны җибәрүчеләр узган елның 11 маенда булган вакыйгалар белән яный икән. Әлеге хәбәргә ачыклык кертү өчен Казан мэриясе матбугат үзәге белән элемтәгә кердек. Дөрестән дә, эвакуация механизмнарын булдыру өчен уку елы дәвамында мәктәпләрдә уку һәм планнан тыш күнегүләр уздырыла. Анда исемсез хатлар килүен дә инкарь итмәделәр. Кичә башкалада дистәдән артык мәктәптә балаларның эвакуацияләнүе билгеле булды. Шулай ук Казан федераль университеты, Казан мәдәният институты студентларының да урамга чыгарылуын ишеттек.

– Хокук сакчылары кабат шундый хәбәрләрне тикшерергә мәҗбүр. Әти-әниләр тагын борчыла. Без аңлыйбыз, өзелгән дәресләр өчен дә борчылабыз. Әмма мондый очракларның уяулыкны какшатуын теләмибез. Бу бит – балалар иминлеге мәсьәләсе. Кайдадыр уку икенче дәрестән башланырга мөмкин. Без баланы мәктәпкә озатканда, теләсә кайсы сигналның җавапсыз калмавына, тикшерелүенә ныклап ышаначакбыз. Мондый янаулар турында балаларына аңлаткан һәркемгә рәхмәт, – диделәр Казан мэриясе матбугат үзәгендә.

Укырга бармый калуга балаларның әллә ни исе китмәсә дә, әти-әниләрнең күңеле тыныч түгел. Балаларның юньләп укыганнары да юк, йә карантин, йә вакцина, йә эвакуация дип борчыла алар. Психикалары бозылып бетә бит, диючеләр дә бар.

– 1 нче сыйныфта укучы кызым – каникулда. Улым иртүк мәктәпкә барырга җыенганда укытучыдан, мәктәпне куркынычсызлык кагыйдәләренә тикшерәләр, дигән смс килде. Баласын алып килергә өлгергәннәргә кире алып китәргә кушты. Мәктәпкә барасы булмагач, улым сөенде инде. Тик безнең күңелгә шом керде. Кайчан мондый хәбәрләр килүдән туктар? – ди балалары 143 нче мәктәптә укучы Резеда исемле укучыбыз.

Куркыныч янавы турындагы хәбәр Казандагы «Адымнар» мәктәбенә дә килгән икән. Беренче дәрес бетәргә өлгергәнче балаларны урамга чыгарганнар. Мәктәп директоры Айдар Шәмсетдинов соңгы елда мондый хатның беренче мәртәбә килүен әйтте.

– Без мондый вакытта балаларны мәктәптән чыгарырга тиеш. Каршыбыздагы уку йорты эвакуация урыны булып кулланыла. Кызганыч, ул да нәкъ шундый янау кабул иткән. Шуңа күрә әти-әниләргә хәбәр итәргә туры килде. Алар балаларын өйләренә алып китте. Полиция хезмәткәрләре бинаны кинологлар белән тикшергәнче, дәресләрне уздырмаячакбыз, – диде Айдар Шәмсетдинов.

Мондый янаулы хәбәрләрне ничек туктатып була дип, Татарстан Иҗтимагый палата рәисе урынбасары Рафил Ногмановның да фикерен белештек.

– Бер нәрсә дә булмаганны белсәк, урамга чыгармас та идек. Мондый очракта балаларны эвакуацияләмичә булмый. Бу эш белән хулиганнар шөгыльләнә. Янаулы хәбәрләрне Украина, Литва, Латвиядән, илнең төрле почмакларыннан җибәрәләр. Интернет аша бүтән илдән килсә, бер нәрсә эшләп булмый. Аларны эзләргә һәм тотарга, Интерпол белән эшләргә кирәк. Җәзасы кечкенә түгел. Әлеге эш белән полиция шөгыльләнергә тиеш. Эзенә төшкән очраклар бар, әмма аз, – ди Рафил Ногманов. – Бу – кешенең хисләре белән уйнау, күңеленә курку кертү. Шартлау була дип, мәктәптән куып чыгару эш түгел. Баланың психологиясенә дә бәрәчәк бит ул. Монда сәяси дошманнар юкмы икән, дип дә уйлап торам. Алар да булырга мөмкин.

Психолог Гүзәл Низамова, әгәр бала мәктәпкә барырга курка икән, бу очракта аны өйдә калдырырга кирәк, ди.

– Куркуыңны әйтү – ул куркаклык түгел. Бу – нормаль хәл. Беренче чиратта, күңелдә тынычлык урнашу мөһим. Икенчедән, әти-әниләрнең мәктәптән, дәүләттән белем алу өчен уку йортын куркынычсыз итүне таләп итүе кирәк. Бу – психологик түгел, күбрәк сәяси сораудыр. Кеше хисләре белән кем уйный? Бер кешеме, әллә тулы системамы – без белмибез. Әмма сорау барыбер кемне тәрбияләүгә кайтып кала. Кем куркыта, кем, мәктәпкә барып, атыш оештыра… Шулай ук сорауны мәгариф системасын бары тестлар дәрәҗәсенә калдырып, кеше кыйммәтләрен алып аткан дәүләткә бирергә кирәк. Мәктәпләр БДИ бирү генә түгел, тәрбия белән дә шөгыльләнергә тиеш. Тимер коймалар, хосусый хезмәтләр куеп кына иминлекне тулысынча тәэмин итеп булмый. Җиңел яшәргә өйрәнгән, психологик яктан тотрыклы булмаган яшьләр йогынтыларга, провокацияләргә бик тиз бирелә. Баланың эмоциональ халәтен онытмыйсы иде. Казан мәктәпләрендәге психологик халәтнең яхшыруын теләргә генә кала. Үз эшен яхшы белгән укытучылар җитми, – ди Гүзәл Низамова.

Бу атнада Татарстан тикшерү комитетының йомгаклау коллегиясе утырышында да 175 нче гимназиядә булган фаҗигане искә төшерделәр.

– Балалар һәм үсмерләр утырырга мөмкин булган деструктив төркемнәрне барлау, профилактикалау – тикшерү комитетының тагын бер бурычы. Мондый җинаятьләргә сәләтле булган кешеләрне ачыкларга кирәк, – диде комитет җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Марсель Дәлкәрнәев.

Сәрия МИФТАХОВА

ЦИФРЛЫ АВЫЛ

Яңалык

Соңгы берничә елда авыл хуҗалыгын цифрлаштыру турында күп сөйлибез. Савым залларын роботлаштыру, кәгазь варианттагы документларны бер системага туплау, терлекләрнең электрон паспортын булдыру, өйдән чыкмый гына субсидияләр, кредитлар алу… Авыл хуҗалыгында цифрлаштыру тагын ничек тормышка ашырыла? Ул кемнәргә кагыла һәм гади халык аны ничек тоячак? Без әнә шуны ачыкладык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Бу төр үзгәрешләр, беренче чиратта, бизнеска кагыла, – ди республика мәгълүмати-исәпләү үзәге директоры Нияз Хәлиуллин. – Бу күренешне цифрлы трансформация дисәк, дөресрәк булыр һәм ул фикерләү үзгәрү дигәнне аңлата. Монда без тармактагы идарә итүдә үзгәрешләрне күз алдына китерәбез. Ягъни мәгълүматлар нигезендә тармак белән идарә итүгә караш үзгәрәчәк.

Әлегә тармакта нинди җитешсезлекләр бар? Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында цифрлаштыру өчен җаваплы җитәкче фикеренчә, хәзерге вакытта күп кенә мәгълүматлар системага я барып җитми, яки югала. Нәтиҗәдә дөрес булмаган карарлар кабул ителә. Икенчедән, тегe яки бу субсидияне алыр өчен бик күп документлар җыеп тапшыру эшне катлауландыра һәм вакытны суза. Өченчедән, эшмәкәрләр белән башкарма хакимият органнары арасында бәйләнеш юк.

Ничек хәл итәсе? Җитешсезлекләр «Мои субсидии» сервисы аша хәл ителә. Аның ярдәмендә документларны өйдә торган килеш кенә дә җиткереп була. Тиз, ташламалы кредитлар алу буенча да алга китеш сизелерлек булачак.

– Алга таба без кредит бирүне җитештерү күрсәткечләренә нигезләнеп тизләтә алачакбыз. Мәсәлән, бер фермерның 100 баш мөгезле эре терлеге бар, ләкин залогка салырлык бер нәрсәсе дә юк, ди. Тик аның җитештерү күрсәткечләре бар. Булган мәгълүматларга таянып, без бу хуҗалыкта бер елдан соң нинди вазгыять булуын чамалап, аңа кредит алуда ярдәм кулы суза алачакбыз, – ди Нияз Хәлиуллин.

«Агрополия» аграрийлар өчен бердәм цифрлы платформасы исә фермерларга республика һәм федераль башкарма хакимият органнары белән эшчәнлек алып барырга ярдәм итәчәк.

Билгеле булганча, 1,5 ел элек хайваннарны барлап, аларны махсус саннар белән билгели башладылар. Терлекләрне идентификацияләү – шулай ук цифрлаштыруның бер чагылышы.

– Бүгенгә республикадагы терлекләрнең 35 процентына уникаль номерлар бирелгән. Тиздән Татарстандагы терлек санына карата сораулар бөтенләй булмаячак. Теге яки бу терлекнең авырлыгы, әти-әнисе, уртача күпме сөт бирүе, кайчан бозаулаячагы, нинди прививкалар ясалганлыгы, авырулары, үлүе – барысы да электрон паспортта күрсәтеләчәк. Сер түгел, продукция базарында үлгән мал сату очраклары да бар. Барлык терлекләрнең дә электрон паспорты булгач, мондый очракларга юл куелмаячак.

Нияз Хәлиуллин киләчәктә бу яңалыкның шәхси хуҗалыкларга да кагылачагын әйтте.

Яңалыклар күпчелек очракта бизнес, эшмәкәрләргә кагылса да, тармактагы үзгәрешләрне узган ел шәхси хуҗалыкларга да сизәргә туры килде. Алар терлекләр тоткан өчен бирелә торган субсидияне «Мои субсидии» сервисы аша эшләделәр. Дөрес, яңалык күп кешедә канәгатьсезлек уяткан иде. Хуҗалык кенәгәсен электрон форматка күчерү авыл советында эшләүче хезмәткәрләрнең дә сабырлыгын шактый сынады. Халыкка да тегe яки бу документны эзләп, шактый борчылырга туры килде.

– Яңалык һәрвакыт авыр кабул ителә. Бу табигый, – ди белгеч безнең соравыбызга каршы. – Башкарып чыкканчы, әлеге эшне эшләп булуны бөтенләй күз алдына китермәделәр. Бик зур каршылык булды, ләкин һәр кеше моның иртәме-соңгы кабул ителәсен белә иде. Башкарып чыккач, рәхмәт сүзләре дә күп ишеттек.

Нәрсә үзгәрәчәк? Нияз Хәлиуллин әйтүенчә, күпчелек эшнең электрон форматка күчүе коммуникацияләр, карарлар кабул итү һәм дәүләт ярдәмен алу тизлеген үзгәртәчәк. Мәгълүматлар да ачык булачак.

– Рәсми статистика реаль тормыштан еш кына аерыла. Ә саннар компьютерга күчерелгәч, барысы да ачык булачак. Узган ел, мәсәлән, әлеге эш нәтиҗәсендә 100 мең гектардан артык файдаланмый торган җир мәйданнары ачыкланды. Әлегә авырлыклар да бар. Теләсә нинди яңалык кереп китсен өчен, вакыт кирәк. Икенчедән, кайбер районнарда интернет начар эшли. Өченчедән, компьютерлар җитми, булганнары да иске. Дүртенчедән, кадрлар кытлыгы. Бу – иң зур проблемаларның берсе. Авыл җирендәге заманча предприятиеләрдә хезмәт хаклары шәһәрдәгегә караганда күбрәк тә әле. Искечә эшләгән оешмаларга кадрлар беркайчан да кайтмаячак. Кайткан очракта да, алар анда озак эшләмәячәкләр, – ди Нияз Хәлиуллин.

Авыл хуҗалыгына цифрлаштыру тирәнрәк үтеп керү эш урыннары кыскаруга китермәсме? Авылда сыер савучы апа эшсез калмасмы? Бу сорауга Нияз Хәлиуллин менә нәрсә дип җавап бирде:

– Юк. Киресенчә, кешеләр җитми. Бөтен эшне дә тулысынча роботлаштыруга күчереп бетереп булмый. Бу мөмкин дә түгел. Саву залында сыер савучының хезмәте барыбер кирәк булачак, ләкин аның эш тәртибе үзгәрәчәк. Югары квалификацияле сыер савучы югары хезмәт хакы алып эшләячәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Якын киләчәктә агросәнәгать комплексын танымаслык итеп үзгәртергә сәләтле булган төп 5 алдынгы технология

- Савым роботлары. Әлегә безнең республикада ул якынча 3 процентны тәшкил итә. Татарстанда, Россиядә беренчеләрдән булып, роботлаштырылган ферма төзелде.
- Пилотсыз техника.
- Зур мәгълүматлар белән эшләүче система.
- Космомониторинг. Ул бар һәм без аның белән күптәннән шөгыльләнәбез. Мәсәлән, кырларның электрон паспортларының 90 проценты электрон форматта эшләнә.
- Белем. Ун ел эчендә классик төрдә белем алу үзгәрәчәк.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы прокуратурасы федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек идарәсенең эшкуарлар хокукларының үтәлешенә күзәтчелек бүлеге (2 номерлы) өлкән прокуроры **Әбҗәлилов** Марат Равил улына; Татарстан Республикасы прокуратурасы җинаять җәзаларын үтәтүнең законлылыгына күзәтчелек бүлеге прокуроры **Әхмәтшин** Артур Сәет улына; Татарстан Республикасы прокуратурасы кадрлар бүлеге прокуроры **Вәлиуллина** Гүзәл Инил кызына; Татарстан Республикасы прокуратурасы федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек идарәсенең икътисад өлкәсендә законнарның үтәлешенә күзәтчелек бүлеге (4 номерлы) башлыгы **Гыйльманов** Тимур Наил улына; Татарстан Республикасы Актаныш районы прокуроры урынбасары **Заһретдинов** Руслан Бәйрәмгали улына; Татарстан Республикасы Чистай шәһәр прокуроры урынбасары **Олюшкина** Наталья Евгеньевнага; Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савиново районы прокуроры урынбасары **Селиваненко** Анастасия Александровнага; Татарстан Республикасы прокуратурасы планлаштыру, хезмәт, финанслау, бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге башлыгы урынбасары **Гыйлаҗев** Илдар Кирам улына; Татарстан Республикасы прокуратурасы гомуми һәм махсус эш башкару бүлеге баш белгече **Зарипова** Ольга Шәриф кызына; Татарстан Республикасы прокуратурасы гомуми һәм махсус эш башкару бүлеге баш белгече **Шкапина** Наталья Владимировнага; Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының эш башкару һәм режим идарәсе башлыгы урынбасары – бүлек башлыгы (гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге), эчке хезмәт полковнигы **Әхмәтшина** Люция Зәкәрия кызына; Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы хезмәткәрләре: милек идарәсенең дәүләт милкен арендага алу һәм сату бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Буслаева** Ирина Александровнага; стратегик планлаштыру һәм хосусыйлаштыру бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Вафина** Нинэлла Илдус кызына; милек идарәсенең дәүләт милкеннән файдалану бүлеге башлыгы **Мизакова** Неля Мансур кызына; Алексеевск районы кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе **Хәйбуллин** Илнур Мингаяз улына; «Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Ведомстводан тыш сак идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы – Чистай районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы **Беспалов** Юрий Петровичка, «Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Ведомстводан тыш сак идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы – Буа районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы **Кәлимуллин** Вәгыйб Галимулла улына, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе «Ак Барс» махсус билгеләнештәге мобиль отрядының инженерлык-техник бүлекчәсе полицейские (кинологы), полиция прапорщигы **Мәҗитов** Радик Фирдәүс улына; **«Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыяте коллективына; Түбән Кама шәһәренең «Шәһәр электр транспорты» муниципаль унитар предприятиесе коллективына;** Чаллы шәһәренең «Олимпийский» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе директоры урынбасары **Бухарова** Татьяна Ивановнага; Казан шәһәре «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесенең торак-эксплуатация участогы башлыгы **Рыбалкина** Марина Александровнага; «Россия почтасы» акционерлык җәмгыяте «Татарстан почтасы» филиалы почта элемтәсе идарәсенең Казан районара почтамты 422792 Чыты почта элемтәсе бүлекчәсе почтальоны **Сөнгатуллина** Гөлсимә Галимҗан кызына; «Татарстан Республикасының Янгыннан саклану хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе янгынга каршы көрәшү хезмәтенең Казан отряды Зеленодольск муниципаль районының «Яңа Тура» технополисы» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте территориясендә янгынга каршы көрәшү хезмәте аерым пост башлыгы **Беганов** Андрей Викторовичка; Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе кадрлар, тәрбия эше һәм һөнәри белем бирү идарәсенең тәрбия эше һәм коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау бүлеге башлыгы, эчке хезмәт полковнигы **Долганов** Андрей Васильевичка; Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе граждан оборонасы чаралары һәм халыкны саклау идарәсенең граждан оборонасы бүлеге башлыгы урынбасары **Ибраһимов** Таһир Мөнирҗан улына; «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары – сатып алуларны тәэмин итү идарәсе башлыгы **Моратаева** Алия Мөхәммәдали кызына; «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «Юл хәрәкәте иминлеге» бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре **Хөсәенова** Регина Зөфәр кызына; «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары **Шигин** Леонид Борисовичка; «Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Ведомстводан тыш сак идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесенең Югары вазыйфаи затларның куркынычсызлыгын тәэмин итү үзәге хезмәткәрләре: беренче бүлекнең (куркынычсызлыгын тәэмин итү) 1 номерлы бүлекчәсе өлкән инспекторы, полиция подполковнигы **Галимов** Ришат Илдус улына; икенче бүлекнең (тикшерү һәм хезмәттәшлек) 1 номерлы бүлекчәсе инспекторы, полиция өлкән лейтенанты **Гафурҗанов** Дамир Рөстәм улына; беренче бүлекнең (куркынычсызлыкны тәэмин итү) 4 номерлы бүлекчәсе өлкән инспекторы, полиция майоры **Хисмәтуллин** Рафаэль Рәвхәт улына; Буа районара тикшерү бүлеге җитәкчесе урынбасары, юстиция полковнигы **Әскәров** Дамир Мөслим улына; икенче контроль-тикшерү бүлегенең икенче бүлекчәсе (оештыру-статистика) өлкән инспекторы, юстиция майоры **Попов** Максим Анатольевичка; Биектау районара тикшерү бүлегенең аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе, юстиция подполковнигы **Фатыйхов** Марсель Юныс улына; «Минзәлә автотранспорт предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Кәримов** Рамил Габделхак улына; «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Чаллы электр челтәрләре» филиалы баш инженеры **Сәлахов** Марат Марс улына; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Эшләр идарәсенең гомуми бүлеге өлкән белгече **Хәсәнова** Әлфия Мирзанур кызына; «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгы хезмәткәрләре: административ-хуҗалык хезмәте башлыгы **Акмалетдинова** Альбина Наил кызына; конструкторлык бүлеге инженер-конструкторы **Башкиров** Константин Александровичка; җитештерү цехының электр һәм газ белән эретеп ябыштыручысы **Гәрәев** Гөлүс Геннадьевичка; оешмалар, хисап бирергә тиешле затлар белән хисапларны исәпкә алу, башка бухгалтерлык операцияләре буенча баш белгече **Камалетдинова** Сабина Рәис кызына; Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары **Ротарь** Мария Сергеевнага; Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе кадрлар белән, мәгълүмат-аналитик яктан тәэмин итү һәм эш башкару төбәкара бүлеге консультанты **Сабирова** Айгөл Илгиз кызына; Казан шәһәр Думасы аппаратының халыкара һәм муниципаль элемтәләр идарәсе башлыгы **Галиәхмәтов** Руслан Рузәл улына; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары **Макаров** Виктор Витальевичка; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе урынбасары – хокук идарәсе башлыгы **Яковлев** Виктор Иосифовичка; Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге башлыгы **Гаризов** Ильяс Гомәр улына; Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының ордер-рөхсәтләр бирү секторы мөдире **Гыйльманов** Ранас Әсхәт улына; «Новый Град» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең инженерлык эзләнүләре бүлеге башлыгы **Данилов** Алексей Михайловичка; «Татавтодор» акционерлык җәмгыяте җитештерү һәм төзелеш бүлегенең капиталь төзелеш буенча әйдәүче инженеры **Латыйпов** Рамил Илгиз улына; «ГарантСтройМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Хуҗин** Хәлил Галиәхмәт улына; Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы хезмәткәрләре: икътисади анализ һәм дәүләт программалары формалаштыру идарәсенең максатчан программалар формалаштыру бүлеге башлыгы **Даутова** Динә Максуд кызына; төзелеш комплексын үстерү идарәсенең төзелеш комплексында үзара хезмәттәшлек бүлеге әйдәүче консультанты **Зиннуров** Рафаэль Акрамттин улына, оештыру эше һәм төбәкара элемтәләр бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Исмәгыйлев** Ильяс Рәдиф улына, «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәрләре: Менделеевск филиалы бүлеге башлыгы **Зиннәтуллина** Әлфия Рәшит кызына; Чирмешән филиалы бүлеге башлыгы **Ишеева** Ирина Николаевнага; Аксубай филиалы бүлеге башлыгы **Мирякурова** Надежда Валерьевнага; Ютазы филиалы бүлеге башлыгы **Сәлимгәрәева** Ирина Васильевнага; «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Гамәли тикшеренүләр институты» аерымланган структур бүлекчәсе баш фәнни хезмәткәре **Габделхаков** Валерьян Фәрит улына; «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе директорының административ-хуҗалык часте буенча урынбасары **Кәримов** Илнур Илгизәр улына; Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының матди-техник тәэминат бүлеге башлыгы **Мөхәммәтдинов** Ленар Марат улына; «Апасның туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры **Ногманов** Рамис Госман улына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

***

«Нурлат-Сөте» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Иске Чаллы бүлекчәсе идарәчесе (берьюлы агроном вазыйфаларын башкаручы) (Татарстан Республикасының Нурлат районы) **Герасимов** Анатолий Аркадьевичка, «АЗНАКАЙ» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте агрономы (Татарстан Республикасының Азнакай районы) **Гыймадиев** Альберт Гыйлаҗетдин улына, «Чәчер» ябык акционерлык җәмгыяте агрономы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Солтанов** Радик Риф улына, «АЗНАКАЙ» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте агрономы (Татарстан Республикасының Азнакай районы) **Таҗиәхмәтов** Рамил Харис улына, «Саф» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте агрономы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Тимеров** Мөхәммәтгали Тимер улына **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе беренче контроль-тикшерү бүлеге җитәкчесе урынбасары, юстиция майоры **Муллакаев** Тимур Радик улына, Татарстан Республикасы Конституция суды аппаратының фәнни-аналитика бүлеге башлыгы **Садыйков** Илдар Фиркать улына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 33 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Вәлиәхмәтова** Зөлфия Әнвәр кызына, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Россия Герое А.В.Козин исемендәге 7 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Дедюк** Инна Вячеславовнага, Чуашстан Республикасы Комсомол районының «Урмай урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы **Камалетдинов** Фәниз Хасиятулла улына, Татарстан Республикасы Буа шәһәренең «Кайбер фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 1 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорының уку-укыту эше буенча урынбасары **Князева** Татьяна Михайловнага, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «3 номерлы Урыссу урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең химия һәм биология укытучысы **Колобова** Елена Николаевнага, Казан шәһәре Яңа Савин районының «49 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең биология укытучысы **Семкичева** Любовь Ивановнага, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Советлар Союзы Герое Ханжин Павел Семенович исемендәге 1 номерлы Тәтеш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Фәткуллов** Илдар Роберт улына, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Югары Лашчы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Шәрәфетдинова** Илсөяр Ирек кызына, «А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Юсупов** Валерий Беляловичка **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясе директоры – онкология, радиология һәм паллиатив медицина кафедрасы мөдире, профессор, медицина фәннәре докторы **Хәсәнов** Рөстәм Шамил улына **«Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча медицина-санитария часте» федераль казна сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасы башлыгы – поликлиника (Казан шәһәрендә урнашкан) табибы **Мерикова** Елена Федотовнага **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив җәмәгать эшчәнлеге өчен хезмәт ветераны **Фомин** Анатолий Алексеевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен **Әминов** Фелоред Владимир улы; фән һәм мәгарифне үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-тикшеренү эшләре идарәсе башлыгы **Янбаев** Фатих Мискадес улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме тугызынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы егерме тугызынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 40361-8 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында.
3. 2021 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында доклад.
4. Хөкүмәт сәгате: «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру турында».
5. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 264-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 259-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 269-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 270-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 265-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 267-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 271-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.
13. «Россия Федерациясе тимер юл транспорты уставы» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 43217-8 номерлы федераль закон проекты хакында («йөрт һәм түлә» шартларында тимер юл транспортында йөртүгә шартнамәләр төзү турында).
14. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.17^1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 28683-8 номерлы федераль закон проекты турында (алкоголь продукциясен һәм спиртлы продукцияне сату өлкәсендә административ җаваплылыкны төгәлләштерү хакында).
15. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 41446-8 номерлы федераль закон проекты турында (йорт хайваннарын тоту таләпләрен үтәмәгән өчен административ җаваплылык билгеләү максатларында).
16. «Көнкүреш билгеләнешендәге пиротехник эшләнмәләрне куллану куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 46601-8 номерлы федераль закон проекты хакында.
17. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 51079-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт оборона заказы буенча продукция бәясе хакында тәкъдим һәм аны җитештерү чыгымнары турында мәгълүмат бирмәгән өчен җаваплылык билгеләү хакында).
18. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 42172-8 номерлы федераль закон проекты турында (кече һәм урта эшкуарлык субъектларына административ җәза билгеләүне камилләштерү өлешендә).
19. «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыруга чыгымнарны финанслашу өлешендә үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Владимир өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең мөрәҗәгате хакында.
20. «Пычраткыч матдәләр калдыкларын квоталау буенча тәҗрибә үткәрү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына атмосфера һавасын пычратуны киметү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 45652-8 номерлы федераль закон проекты хакында (федераль башкарма хакимият органнары вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә).
21. «Этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 16 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 555-8 номерлы федераль закон проекты хакында (алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмаларга шушы продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләр чикләрен билгеләү турында хәбәр итү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).
22. «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 57343-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт преференцияләре һәм муниципаль преференцияләр бирү максатлары өлешендә).
23. «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча тәҗрибә үткәрү турында» Федераль законның 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 43000-8 номерлы федераль закон проекты турында (салым органында һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куелу тәртибен камилләштерү хакында).
24. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179^4 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 48712-8 номерлы федераль закон проекты хакында (шәһәр рельслы транспорт инфраструктурасын модернизацияләү эшләрен финанслау чыганагы белән тәэмин итү юлы ярдәмендә шәһәр рельслы транспорт инфраструктурасын яңартуны һәм үстерүне кызыксындыру өлешендә).
25. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 83 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 48750-8 номерлы федераль закон проекты хакында (UEFA Чемпионнар лигасының финал матчын әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле рәвештә салым ташламаларын билгеләү турында).
26. «Чечен Республикасы Грозный шәһәренең район судлары исемнәрен алмаштыру турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чечен Республикасы Парламенты закон чыгару инициативасы хакында.
27. «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 50918-8 номерлы федераль закон проекты турында (хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юк иткәндә хайваннарны һәм (яисә) терлекчелек продукциясен тартып алу тәртибен төгәлләштерү өлешендә).
28. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 10 феврале
№ 1319-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп чикләнмәгән срокка түбәндәгене сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Авиатөзелеш суд районы буенча:

3 нче суд участогына – Харьков Алексей Анатольевичны.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 10 феврале
№ 1320-VI ДС

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең
11 февраль, 2022 ел, №167/1423 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай территориясендә оештырылган № 554 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе составы резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Азнакай территориясендә оештырылган № 554 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе составы резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр итә. Тәкъдимнәр һәм кирәкле документлар кабул итү Татарстан Республикасы Азнакай районы территориаль сайлау комиссиясе тарафыннан 2022 елның 14 февраленнән 28 февральгә кадәр эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты – 12.00–13.00 сәгатькәчә) хәл ителә:

Территориаль сайлау комиссиясе (ТИК) атамасы	Территориаль сайлау комиссиясе адресы
Татарстан Республикасы Азнакай районы ТИК	423330, ТР, Азнакай ш., Ленин ур., 22 й. (код 8-85592) тел.: 7-26-31

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 29 статьясындагы 1 пунктындагы таләпләргә туры килмәүче затлар, тәгаенләп әйткәндә:

– Россия Федерациясе гражданлыгына ия булмаган затлар, шулай ук чит ил гражданлыгына ия булучы яки Россия Федерациясе гражданинының чит дәүләт территориясендә даими яшәүгә хокукын раслаган башка документка ия булучы Россия Федерациясе гражданнары;

– законлы көченә кергән суд карары нигезенә эшкә сәләтсез, эшкә сәләте чикләнгән дип танылган Россия Федерациясе гражданнары;

– 18 яшькә җитмәгән Россия Федерациясе гражданнары;

– дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары, җирле үзидарә органнары депутатлары;

– сайланылулы вазыйфаи затлар, шулай ук җирле хакимиятләр башлыклары;

– судьялар (отставкадагы судьялардан тыш), прокурорлар;

– суд карары нигезендә комиссияләр составыннан чыгарылган затлар, шулай ук комиссияне таркату нәтиҗәсендә хәлиткеч тавыш хокукы белән комиссияләр әгъзалары вәкаләтләрен җуйган затлар (комиссия тарафыннан закон бозулар өчен суд тарафыннан үзләренә карата гаепләрнең юклыгы билгеләнгән затлардан тыш) – тиешле суд карары законлы көченә кергәннән соң биш ел эчендә;

– үзләреннән хөкем җәзасы алынмаган затлар, шулай ук сайлаулар һәм референдумнар турында законны бозган өчен суд тәртибендә административ җәзага тартылган затлар – административ җәза билгеләү турында суд карары законлы көченә кергәннән соң бер ел эчендә, кандидатуралары кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертү өчен кирәкле документлары булмаган кандидатуралар участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кертү өчен кирәкле документлар исемлеге

Сәяси партияләр, аларның төбәк бүлекләре, башка структур подразделениеләре өчен:

1. Сәяси партиянең яки төбәк бүлегенең, сәяси партиянең башка структур подразделениесенең участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында сәяси партия уставы таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.
2. Кандидатуралар турында тәкъдим сәяси партиянең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесе тарафыннан кертелеп, сәяси партия уставында мондый тәкъдим кертү мөмкинлеге күздә тотылмаганда – сәяси партиянең төбәк бүлегенә, башка структур подразделениесенә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертүгә вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле сәяси партия органының әлеге вәкаләтләрне бирү турында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.

Башка иҗтимагый берләшмәләр өчен:

1. Иҗтимагый берләшмәнең гамәлдәге уставының нотариуста расланган яки иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле органы раслаган күчермәсе.
2. Иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары яисә төбәк бүлегенең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының яисә иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә иҗтимагый берләшмә исеменнән мондый карар кабул итүгә хокук бирелгән иҗтимагый берләшмәнең башка структур подразделениесе карары.
3. Кандидатуралар турында тәкъдимне иҗтимагый берләшмәнең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесен кертеп, иҗтимагый берләшмә уставында 2 пунктта күрсәтелгән мәсьәлә җайга салынмаганда – иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү буенча вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле иҗтимагый берләшмә органының мондый вәкаләтләрне бирү турында карары һәм әлеге вәкаләтләр бирелгән органның участок сайлау комиссияләре составлары резервына тәкъдимнәр кертү турында карары.

Участок комиссияләре составлары резервына кандидатуралар кертү хокукының башка субъектлары өчен

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары, яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыны буенча сайлаучылар җыелышының беркетмәсе. Сайлаучылар җыелышы беркетмәсенең формасы Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, №152/1137-6 карары (Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 1 ноябрь, 2017 ел, №108/903-7 карары редакциясендә) белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә №3 кушымтада китерелгән.

Моннан тыш кандидатуралар кертү хокукының барлык субъектлары тарафыннан түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш:

1. Россия Федерациясе гражданинының хәлиткеч тавыш хокукы белән участок сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләнүенә, участок комиссияләре составлары резервына кертүгә язмача ризалыгы (Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, №152/1137-6 карары (Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 1 ноябрь, 2017 ел, №108/903-7 карары редакциясендә) белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә №1 кушымта).
2. Россия Федерациясе гражданины паспорты яки кандидатурасы участок комиссияләре составлары резервына кертү өчен тәкъдим ителгән затның гражданлыгы һәм яшәү урыны турында мәгълүматлардан торган Россия Федерациясе гражданины паспортын алыштыручы документы күчермәсе.

Искәрмә. Документлар үрнәкләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына «Сайлау комиссияләре» бүлегендәге «Участок комиссияләре составлары резервы» «2022 елда участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә кертү» бүлекчәсенә урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе

КОТЛЫЙБЫЗ!

Шәриф Габдрахман улы ӘХМӘТҖАНОВка – 90 яшь!

Гомерен халкыбызга армый-талмый хезмәт итүгә, сәүдә тармагын үстерүгә багышлаган мөхтәрәм шәхес ул. Балтач районының Пүскән авылында туып-үскән егетне башта Лаеш халкы үз күрә, гади хезмәткәрдән Райпотребсоюз җитәкчесе кәнәфиенә кадәр күтәрелә һәм тора-бара Кукмарага шул ук вазыйфага күчерелә. Кырык елдан артык, көнне төнгә ялгап, булсын дип, халкыбыз җитеш, матур тормышта яшәсен дип хезмәт итә. Тормыш иптәше, Кукмара төбәге кызы Роза аңа ныклы терәк, хезмәткә рухландыручы була, ул да барлык гомерен халыкка хезмәт итүгә – почта эшенә багышлый. Ике ул үстерәләр. Шамил дә, Айрат та – халкыбызның мактанычы, үз эшләренең чын осталары, тату, бердәм гаилә башлыклары.

Шәриф Габдрахман улы Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде, ул – Россиянең сәүдә отличнигы, РСФСРның атказанган сәүдә хезмәткәре, «Фидакарь хезмәт өчен» медале, бик күп Мактау грамоталары иясе.

Шәриф абый безнең күңелләргә елмаеп, якын итеп, үз итеп сөйләшүче булып керде һәм шулай булып кала да. Юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз!

Шәриф абыйның тормыш иптәше Роза апа былтыр бакыйлыкка күчте. Үзе хәзер – балалары тәрбиясендә. Аларга сабырлык, эшчәнлекләрендә уңышлар насыйп булсын!

Танышлары, фикердәшләре

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Күнегелгән нәрсә

Палата номеры

Палата номеры без күнеккәнчә ишекнең үзенә түгел, ә ишек янындагы стенага зур итеп язып куелган. Миннән дә зуррак ул. Күрми калу һич мөмкин түгел. Тик мин аны башта күрмичә йөрдем. Шәфкать туташы елмаеп төртеп күрсәткәч… Юк, артык нык аптырамадым инде… Мин үземдә Ходай тарафыннан бирелгән табигый ахмаклыкның чамасыз икәнен белә идем. Моңа тагын бер кат ышандым гына. Ләкин гыйллә анда гына булып чыкмады, башкалар да палата номерын тиз генә таба алмыйча нәкъ минем хәлгә кала икән.

Гадәттә, ишекнең өске ягындарак палата санын күрсәткән кечкенә шакмак эләләр бит инде. Кайда да шулай бу. Һәм без инде күнегеп беткәнбез, кайсы хастаханәгә барып эләксәк тә, без бүлмә номерын эзләп шунда карыйбыз. Тапмасак, «юк икән» дип уйлап ары китәбез. Башка җирдән эзләп интекмибез.

Мин моннан үземчә кечкенә бер нәтиҗә ясадым: сине күрсеннәр өчен зур булуың гына җитми, зур һәм матур (уңган, акыллы, талантлы, оста һәм башкалар) булуың бөтенләй мөһим түгел, сине күрсеннәр өчен кеше күзе төшә торган урында булуың кирәк. Өч тиенгә тормаслык нәрсәләрнең дә кайчагында бик популяр булуын менә шуның белән аңлатып була. Гомумән, моның белән бөтен нәрсәне дә аңлатырга мөмкин.

Бер генә нәтиҗә ясамадым әле мин моннан. Бер гади генә күренештән әллә нәрсәләр чыгарып була икән. Кайчагында. Монысы икенче нәтиҗә буладыр инде… Үзеңнән зуррак нәрсәләрне күрү күпкә кыенрак. Бигрәк тә ул сиңа якын булса. Янәшәңдә торса. Хәтта күргән очракта да син аны бар тулылыгында күреп бетерә алмыйсың, бер өлешен генә күрәсең. Бар тулылыгында күрә алу өчен ераккарак китеп карарга кирәк.

Өченче нәтиҗә дә бар әле. Кешеләр: «Ул бит бар», – дип әйтсеннәр өчен, синең булуың, зур булуың, якында гына торуың җитми. Кешеләрнең сине күрүе кирәк. Күрәләр икән – син бар, күрмиләр икән – юк.

Лифт

Мин яшәгән йортта узган җәй лифтны алыштырдылар. Яңа, яхшы, рәхәт. Килеп керү белән – күзгә. Фатирыңнан ничек чыгып китәсең, ничек кайтып керәсең – барысы да күз алдында. Ләкин бу лифт үзе дә күзгә кебек булып чыкты…

Башка җаен тапмаганнармы инде, фикерләре чуалган чак булганмы, төзүчеләр аз гына хата җибәргән. Монда, әйтик, алтынчы катка менү өчен «7» санына басарга кирәк. Җиденчегә менәм дисәң – сигезгә. Без башта бик этләндек инде. Тора-бара күнегеп киттек, әллә ни кыенлыгы юк бит инде. Үзең менәргә теләгән кат санына берне өстисең дә – вуаля!

Күп тапкырлар кабатланса, теләсә нинди хата да дөреслек булып тоела башлый икән. Үзенә күрә бер канунга әверелә. Бездә дә шулай: алтынчы катка менәргә телисең икән – җидегә бас, җиденчегә теләсәң – сигезгә. Ләкин лифт кайвакыт саташып китә дә алтыга бассаң – алтынчы катка, җидегә бассаң, җиденчегә алып менә. Дөрес бит инде, нәкъ шулай булырга тиеш. Ләкин бу аның ялгышуы булып тоела. Сирәк кабатланган дөреслек хата булып күренә башлый.

Кайчагында миннән: «Нәрсә ул дөреслек?» – дип сорыйлар. Хәзер моңа әзер җавабым бар. Дөреслек ул – даими кабатлана торган ялгышлык. Бәлки, бик үк хаклы түгелмендер, хаталанамдыр инде… Тик мин даими рәвештә хаталанам…

vk.com

ТАУ ЯГЫ

Республикабызның Яшел Үзән районына кергән Норлат зонасыннан башланган, Идел буйлап Ульян өлкәсенә кадәр җәелгән биләмәсе Тау ягы дип йөртелә. Мин үзем дә шул төбәктән. Балачакта «Таулар да юк бит инде, нишләп шулай атала икән?» дигән сорауны еш ишетә идем. Соңрак тарих битләреннән бу төбәкнең катлаулы да, фаҗигале дә чор кичергәнен белдем.

Кайбыч районының Хуҗа Хәсән авылында туып үскән, гомеренең бер өлешен туган як тарихын өйрәнүгә багышлаган Вячеслав ДАНИЛОВ белән шул хакта сөйләшәбез.

:: Вячеслав Власович, чыннан да, бу төбәк ни өчен Тау ягы дип атала?

– Тарих битләреннән күренгәнчә, бу термин Идел Болгарстаны яшәгән чорларда ук кулланылган. Болгар шәһәре Иделнең сул як ярында урнашкан. Шул яктан карaганда, елганың уң як ярында татарлар яшәгән җирләр төрле биеклектәге таулар белән капланган кебек. Аннан Чабаксар, Козловка, Зөя калкулыклары, Ослан, Кама Тамагы, Сөйки, Тәтеш, Ундор, Сембер һәм Жигули (Җәяүле) таулары күренеп тора.

:: Тау ягын ныклап өйрәнергә керештегез кебек. Нәрсә этәрде?

– Башта авыл тарихы белән кызыксынып киткән идем. Бу эш белән шөгыльләнгән кеше белә: бер авылны гына аерып алып, тарих язып булмый. Бик күп архивларда казынырга туры килде. Актарына торгач, бу якның галимнәр тарафыннан бик аз өйрәнелгәнен аңладым. Ике китабым дөнья күрде инде. Халык хозурына чыга алмый яткан байлыгым байтак әле. Яңалыклар да булгалап тора. Әле күптән түгел генә, Мәскәү – Казан юлын төзегәндә, Кайбыч районындагы Акхуҗа белән Мәми авыллары янында борынгы зиратка тап булдылар. Тарихыбыз юкка чыкканчы, өйрәнәсе иде. Моның өчен шартлар да бар дип әйтергә мөмкин. Хуҗа Хәсән авылында татар керәшеннәре музее эшләп килә. Белгечләр белән тәэмин ителсә, Татарстан Республикасы музее филиалы буларак дәүләт статусы бирелсә, аны тарихчылар өчен база итеп кулланырга булыр иде. Бу җәһәттән 36 күренекле галим һәм башка өлкәләрдәге атказанган хезмәткәрләр имза куйган үтенечне Татарстан Президентына юлладык. Мәсьәләне хәл итүдә Мәдәният министрлыгының ярдәме дә бик кирәк.

:: Әби-бабаларыбыз бу җирләргә кайчан килеп урнашкан?

– 1392 елны Аксак Тимер Идел Болгарстанын тар-мар итә. Юлында очраган авыл-шәһәрләрне җимерә, яндыра, балаларны, хатын-кызларны да аямый. Безнең әби-бабаларыбыз, шул вакытта Тау ягына качып китеп, яңа җирләргә урнашырга мәҗбүр булалар. Хәсән, Мәлик, Кырганбаш исемле өч туган Хуҗа Хәсән, Мәлки, Иске Кырбаш авылларына нигез сала. Хуҗа Хәсәннең уллары Күгеш, Айдар һәм Ислам бүгенге Яшел Үзән районындагы шул исемдәге авылларны төзиләр.

:: Тау ягына «фаҗигале» дигән төшенчә ни дәрәҗәдә туры килә?

– Чыннан да, монда тормыш кайнап торган. Коры җирдән сәүдә юллары үткән. Илчеләр, гаскәрләр дә шушы юллардан йөргән. Мәскәүнең кайбер кенәзләре дә, Емельян Пугачев, Степан Разин гаскәрләре дә бу төбәкне урап үтмәгән. Уйлап карасаң, күпме сугыш, талау, вәхшилек, кан коюы дигән сүз бит бу. Тау ягында күп кенә шәһәрчекләр һәм күзәтү постлары төзелгәнлеге билгеле. Мәсәлән, Гөбенә елгасы буенда Кайбыч районының Шушермә авылыннан ерак түгел Япанча шәһәрчеге булган. Бүгенге Яшел Үзән районына кергән Өтәк авылында рус гаскәрләре белән Казан ханлыгы гаскәрләре көч сынашкан. Бу канкоеш тарих битләренә кереп калган.

:: Казанны басып алуда төп рольне уйнаган Зөя шәһәрчеге ничек төзелә?

– Казан ханы Олуг Мөхәммәт җитәкчелек иткәндә, бу төбәктә күп рус авыллары барлыкка килә, шул исәптән Зөя елгасындагы Макарий монастыре төзелә. Олуг Мөхәммәт тарафыннан бу гамәлләр ханлыкны нигыту йөзеннән эшләнә, әмма турыдан-туры хыянәткә юл ачыла. Тора-бара Тау ягына тулысынча Мәскәү күзәтчелек итә башлый. Зөя шәһәрчеген 1551 елда бер ай эчендә төзиләр. Ныгытма һәм православие храмнары өчен стеналарны кыш көне Углич урманында әзерлиләр, урында ук җыеп карыйлар, бүрәнәләргә номерлар сугалар. 1551 елның язында шәһәр төзеләсе урынга Идел буйлап сал ясап китерәләр. Бу хакта белеп алгач, Тау ягының сигез авылыннан җыелган егетләр ныгытмага һөҗүм ясыйлар. Әмма анда инде кораллы солдатларның иге-чиге булмый, ә болар беркайдан да ярдәм көтә алмый. 1552 елның язында Явыз Иван җитәкчелегендәге рус гаскәрләре Алатырь шәһәреннән Якле елгасы аша чыгып, Карлыга киләләр. Анда үзләренә кушылуларын сорап, авыл кешеләренә бәйрәм ясыйлар. Егетләре Зөя шәһәренә яу белән киткән авыллар да шунда була. Ризалык бирүчеләр күренми. Шуңа үч итеп, сигез авыл халкын тиз генә чукындыралар. Зөягә килеп җитәрәк, Өтәк авылы янында ял итәргә туктыйлар. Илчеләр белән сүз алышканнан, киңәшләшкәннән соң шәһәрчеккә киләләр. Берничә көннән Казанга юл тотып, Андрей Курбский, Серебряный һәм Бәхтияр Зизулин кебек кенәзләрнең гаскәрләре белән кушылалар.

:: Явыз Иван гаскәре Зөягә юл тотканда нинди эзләр калдырган?

– Халкы көчләп чукындырылудан тыш, авыллар туздырылган, җимерелгән, яндырылган. Бола елгасы буендагы – Чәтбаш, Күл Кашы, Бия буендагы Кабык Күпер авыллары янында әле күптән түгел генә шул заманнан калган кораллар – уклар, кылычлар табылды. Ул урыннарда рус гаскәрләре туктап ял иткән.

:: Белгәнебезчә, властька Романовлар династиясе килгәч, башка диндәге халыкларны чукындыруның икенче дулкыны башлана. Шул көннәрнең истәлеге булып, мөселман авылларында да иске керәшен зиратлары бар әле. Олы юл буенда яшәгән Тау ягы халкына бу ни дәрәҗәдә йогынты ясый?

– 1731 елның 23 августында Зөядә үз канцеляриясе белән «Яңа чор чукындыру конторасы» ачыла. Аның беренче җитәкчесе Алексей Раифский була. Контора хезмәткәрләренә чикләнмәгән вәкаләтләр бирелә. Хуҗа Хәсән кешеләренең Петр Ідә тылмач булып хезмәт итүләре билгеле. 1736 елда шундый тылмачлар чукындыру конторасында пәйда була. Массакүләм чукындыру Лука Конашевич җитәкчелек иткәндә бигрәк тә куркыныч төс ала. Татарлар аны «Аксак Каратун» дип йөртәләр. Бу чорда Тау ягында яшәгән татарларның күбесе туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр була. Зөя шәһәрчегеннән ничек булса да ераккарак китәргә җай эзлиләр. Яңа урнашкан җирләрдә авылларының исемнәрен саклап калырга тырышалар. Шулай итеп, бер исемдәге авыллар пәйда була. Кайбер татарлар, көчләп чукындырылудан куркып, Урал якларына ук китеп бара.

:: Тау ягы бүген ничек яши?

– Идел Болгарстанының Тау ягы дип аталган зур гына территориясеннән 1920 елда Татар Республикасына бары тик бер өлеше генә кереп кала: Яшел Үзән районының Норлат зонасы, Югары Ослан, Кайбыч, Апас, Кама Тамагы, Тәтеш, Буа һәм Чүпрәле районнары. Тау ягы республикабызның 10 мең кв. км җирендә урнашкан. Халкы – 265 мең кеше, ягъни Татарстанда яшәүчеләрнең 12 проценты. Монда зур шәһәрләр, индустрия үзәкләре дә юк. Район билгеләнешендәге шәһәрләр – Буа, Тәтеш һәм Зөя. Тау ягы күренекле кешеләре белән мактана ала. Бу җирдән бик күп шәхесләр – союз, федератив республика дәрәҗәсендәге министрлар, галимнәр, композиторлар, архитекторлар, язучылар, Советлар Союзы Геройлары, Хезмәт Геройлары чыккан. Алар белән Хуҗа Хәсән музеенда да танышырга була. Мәсәлән, СССР Халык Комиссарлары Советы рәисе Кыям Абрамов (Буадан), Казахстан гимны авторы, композитор Латыйф Хәмиди (Кайбычтан), мәгърифәтче Каюм Насыйри (Яшел Үзәннән), композитор Сара Садыйкова, беренче татар театрына нигез салучы Газиз Айдарский (Яшел Үзәннән). Исеме легендаларга кергән атаклы ат карагы Шәкүр дә безнең яктан. Җырчылар Галия Кайбицкая, Лена Бичарина, Лидия Әхмәтова, язучылар Ренат Харис, Шәүкәт Галиев тә Тау ягында туып-үскәннәр. Бу исемлекне бик озак дәвам иттерергә булыр иде. Үткәне дә, бүгенгесе дә бик бай Тау ягының.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КҮКТӘ КҮП, Ә СӘХНӘДӘ?

ТАТАРСТАНДА «ЙОЛДЫЗЛЫК» ФЕСТИВАЛЕ БАШЛАНА

Татарстанда әлеге хәрәкәт турында ишетмәгән кеше калмагандыр. Аеруча балалар арасында. Җырлата, биетә, сөйләтә һәм, гомумән, сәхнәне яратырга өйрәтә торган «Созвездие – Йолдызлык» фестивале турында сүзебез. Быел ул уникенче мәртәбә уздырыла.

Узган ел әлеге проектның гала-концертына барып, сөенеп кайттык. Фестиваль Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган иде. Яшь башкаручыларның ретро һәм халык җырларына игътибар итүе, кечкенә генә малай һәм кызларның татар, рус, мари, удмурт халык көйләренә оста басуы сөендерде. Быел ниләр көтәргә соң? Бу турыда «Йолдызлык»ка багышланган матбугат очрашуында сөйләштеләр.

Татарстан Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды башкарма директоры Нурия Хашимова сүзләренчә, «Созвездие – Йолдызлык» телевизион эстрада сәнгате фестивалендә катнашкан балалар кайда да югалып калмый.

– Әлеге проект үзенең географиясе, катнашучылары белән ел да сөендерә. Быел исә булачак йолдызларның саны аеруча күп. Районнарның актив эшләве сизелә. Хәзер бит шәһәр белән авыл арасында аерма калмады – кайда да мөмкинлекләр бар, шартлар яхшы, – диде ул. – Кайчандыр әлеге фестивальдә уңышларга ирешкән балаларның күбесе – бүген инде зур җитәкчеләр, сәнгать өлкәсендә танылган шәхесләр. Алар дөньядагы нинди генә сәхнәләрдә чыгыш ясасалар да, үз дәрәҗәләрен күрсәтә беләләр.

Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгының Стратегик үсеш, проектларга һәм инициативаларга ярдәм итү бүлеге җитәкчесе Динар Хафизов исә фестиваль бай тарихлы булуын искәртте.

– «Созвездие – Йолдызлык» – яшьләрнең сәләтләрен күреп алып, аларны үстерүдә гаять мөһим һәм нәтиҗәле эш башкаручы, бай тарихлы фестиваль. Аның әһәмияте турында бик озак сөйләргә була. Инде тиздән әлеге проект Татарстан районнары буенча үз эшен башлап җибәрәчәк, – диде ул.

Фестивальнең сайлап алу турлары Әлмәт (25–27 февраль), Чаллы (1–2 март), Түбән Кама (6–7 март), Әгерҗе (9–10 март), Чистай (13–14 март), Арча (17–19 март), Казан (15–17 март), Лаеш (22–23 март), Иске Чүпрәле (26–27 март) һәм Яшел Үзәндә (29–30 март) узачак. Катнашучыларны «Вокал-соло», «Вокаль ансамбльләр», «Хореография», «Конферансье», «Җырга иң яхшы музыка», «Иң яхшы җыр тексты» һәм «Иң яхшы видеоклип» номинацияләрендә бәяләячәкләр.

«Йолдызлык»ның жюри рәисе, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Казан консерваториясе профессоры Зилә Сөнгатуллина быел сайлап алу этапларында һәр катнашучыны җентекләп карарга кирәклеген әйтте.

– Минемчә, бу елдан сайлап алу этапларында без тагын да игътибарлырак булырга тиеш. Катнашучыларның саны болай да елдан-ел арта, шуңа күрә сан ягын кайгыртуны кирәк дип санамыйм. Финалга чыннан да лаеклылар, иң сәләтлеләр чыгарга тиеш, – дип аңлатты ул.

Катнашучылар димәктән, быел фестивальдә 50 меңнән артык бала үз көчен сынап карар дип ышаналар. Бу хакта фестиваль хәрәкәтенең генераль продюсеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Дмитрий Туманов әйтте.

– «Созвездие – Йолдызлык» – Татарстанның яшь талантлары өчен мөмкинлекләр мохите. Мондый проектлар Россиядә һәм, гомумән, дөньяда башка юк. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның иҗади элитаны формалаштыруга игътибары зур булу нәтиҗәсендә, проектның йөзләгән лауреаты Татарстанның һәм Мәскәүнең алдынгы уку йортларын тәмамлады. Алар барысы да халыкара дәрәҗәдәге проектларда, иң яхшы телевизион программаларда үзләрен күрсәтеп, дан казандылар, – диде Туманов матбугат очрашуында.

yold.ru

Быел тагын нинди талантлар ачыласын вакыт күрсәтер. 9–13 апрельдә зона этапларында җиңү яулаган катнашучылар, «УНИКС» концертлар залы һәм «Созвездие – Йолдызлык» арт-резиденциясендә очрашып, проектның Гала-концертына чыгу өчен көрәшәчәк. Йомгаклау концерты исә гадәттәгечә 22 апрельдә «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында узачак.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7080 данә
Гомуми тираж – 17126 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 221

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+